**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-985 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1090 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-915 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-370 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 июлендәге ПУ-396 номерлы, 2020 елның 18 апрелендәге ПУ-240 номерлы һәм 2020 елның 12 августындагы ПУ-482 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Н.Н. Хәбиповны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Иванов Евгений Николаевичны – Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш ветеринария инспекторын (килешү буенча);

Ханбиков Илшат Шәрипҗан улын – Су ресурслары федераль агентлыгы Түбән Идел су бассейны идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгын (килешү буенча);

в) Совет әгъзасы Ю.В. Венедиктовның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Гражданн оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең территориаль органы җитәкчесе урынбасары (Татарстан Республикасы кече суднолар буенча баш дәүләт инспекторы) (килешү буенча)»;

г) Совет әгъзасы И.В. Мөстәкыймованың фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Герасимова».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 05 октябрь
№ ПУ-792